**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләр куллану**

Яббарова Н.С.,*Казан шәһәре Яңа Савин районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 146 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе*
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**С**оңгы елларда урта мәктәпләрдә татар теленә өйрәтү буенча яңа информацион технологияләр куллану мәсьәләсе бик еш күтәрелә. Бу техник чаралар гына түгел, һичшиксез укыту процессына яңа караш. Татар телен өйрәтүнең ин төп максатлары - укучыларньң аралашу эшчәнлеген формалаштыру, үстерү һәм белемнәрен практикада куллану.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, үз алдыма күп кенә бурычлар куям. Татар телен практикада кулланырлык дәрәҗәдә үссен өчен, кирәкле шартлар булдырам. Тиешле укыту методикасын сайлап алу, һәр баланьң күпмедер дәрәҗәдә үзенең иҗади эшчәнлеген ачарга мөмкинчелек бирә, татар телен чит тел буларак тирәнтен өйрәнүне активлаштыра.

Компьютерны техник чаралар буларак куллану, татар теле укытуның барлык өлкәләренә дә үтеп керә. Моның шулай булуына шигем юк. Татар теле дәресләрендә информацион технологияләр куллануның эффекты турында курыкмыйча әйтә алам. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен компьютердан башка күз алдына китерү кыен. Ни өчен дисезме? Чөнки компьютер укытуның дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итә, бик күп күләмдә күрсәтмәлекләр булдыру мөмкинчелеге тудыра. Контроль, бик зур күләмдә мәгълүмат чыганагы булып торуы, чыннан да укыту процессында стимул булып тора.

Компьютер, тренажер кебек хезмәт итә, текстлар редакторында инструмент вазифасын үти. Аралашу каналы буларак кулланыла. Аудиовизуаль мәгълүматләр презентациясе ролен дә башкара. Тестлар белән эшләүне тәэмин итә. Компьютер - балага шәхси яктан якын килү өчен дә менә дигән ярдәмче. Укучы, сәләтенә һәм кызыксынуына карап, күңеленә хуш килгән программаны эзләп таба һәм шул юнәлештә белемен камилләштерә. Заманча компьютердагы информация теләсә кемне кызыксындырырлык итеп эшләнгән. Бу исә кирәкле гыйлемне кабул итү һәм үзләштерүне бермә-бер җиңеләйтә һәм тизләтә.

Компьютерларны класстан тыш эшләрдә файдалану уңайлы һәм аеруча нәтиҗәле була. Укучыларның сәләтен һәм кызыксынуларын истә тотып, төрле биремнәр тәкъдим итәргә мөмкин. Моның өчен мәктәп

серверларында һәр укучының һәм укытучының үз электрон почтасын булдыру әһәмиятле. Класстан тыш эш вакытында укучылар берәр темага багышланган конференциягә, музыкаль-әдәби чараларга материаллар әзерлиләр һәм аны электрон почта аша укытучыга җибәрәләр.

Бүгенге җәмгыять тыгыз информация челтәре белән уратып алынган. Баланы шул серле дөньяга якынайту, мәгълүмат белән эшләргә өйрәтү, укучыларга белем бирү белән генә чикләнмичә, аларны эзләнү, тикшеренү, мөстәкыйль эшләүгә тарту безнең мәктәп укытучыларының төп бурычы. Табигатьнең экияти көченә ышанучы ата-бабаларыбыз, иге-чиге булмаган информация кысаларында яшәүебезне могҗиза дип атарлар иде. Ата-бабаларыбыз яшәү дәверендә ала алмаган информацияне, дөрестән дә, без 21 гасырда бер сәгать эчендә шулкадәрле информацияне табып кабул итә алабыз?! Ә без, үз чиратыбызда, укучыларны тиешле интернет ресурсларыннан дөрес файдаланырга, информацион дулкында югалып калмаска, дөрес юлдан читкә китмичә, тышкы яктан җәлеп итүче интернет челтәренә килеп эләкмәскә өйрәтергә тиешбез. Укучыларда уку процессына кызыксыну уяту өчен стандарт методлар белән генә чикләнергә ярамый.

Укучыны татар телен өйрәнүгә кызыксындыруның тагын бер юлы булып, информацион технологияләр куллану тора. Информацион технологияләрнең зур тизлек белән үсүе яшь буынның белемле, иҗади фикер йөртүгә сәләтле булуын таләп итә. Информацион технологияләр куллану укучының мөстәкыйль эшчәнлеген активлаштыра, уңышка ирешергә этәрә, укытучыга дәресләрне кызыклы итеп үткәрергә, иҗади эшләргә, сыйфатлы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Информацион технологияләрдән файдалану дидактиканың фәннилек, күрсәтмәлек, эшлеклелек һәм мөстәкыйльлек принципларын куллану мөмкинлеген бирә. Алар яңа мәгълүмат табуның аеруча әһәмиятле функцияләрен үти, белемен камилләштерә, ныгытуда һәм гомумиләштерүдә, эзләнүләр, тәрбия һәм тикшеренүләр алып баруда, үзгәрешләр кертүдә көчле корал булып тора.

Microsoft Power Point – презентацияләр һәм слайд-фильмнар әзерләүнең график рәвешендә күрсәтелгән пакеты.

Укучылар информатика дәресләрендә аерым темаларны өйрәнеп, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә конференцияләрдә катнашып, укучылар компьютер мөмкинлекләреннән киңрәк файдаланырга күнегә.

Укыту һәм тәрбия процессында компьютер презентацияләре куллану укучыларның дәрес материалын үзләштерүне интенсивлаштыра һәм дәресне сыйфатлы дәрәҗәдә яңача үткәрергә мөмкинлек биреп кенә калмый, такта урынына слайд-фильмнар компьютер экраны аша зур экранга яисә укучының

компьютерына (ноутбук) чыгарыла. Визуаль эчтәлекле дәрес материалы дәресне күз явын алырлык, төпле итә һәм үз чиратында укыту процессын үзләштерүне  көчәйтеп (интенсивлаштырып) җибәрүгә сәбәп була.

Компьютер презентацияләре  укучының игътибарын иң кирәкле мәгълүматка гына әһәмият бирергә эффектлы күрсәтмә үрнәкләр тибындагы күренешләр, схемалар, диаграммалар, график җыелмалар мөмкинчелек бирәләр. Презентация хәтернең берничә төренә: күрүгә, ишетүгә, хискә һәм кайбер очракларда хәрәкәткә йогынты ясый.

Укыту процессында презентацияләрне дәреснең төрле этапларында кулланырга мөмкин. Презентацияләр булдыру укытучыга иҗади якын килүне һәм компьютер  мөмкинчелекләрен тирәнтен белүне таләп итә. Компьютер презентацияләрен куллану күп кенә бурычларны үтәргә булыша:

- укытуның сыйфатын үстерү;
- татар телен өйрәнүне тиешле дәрәҗәгә күтәрү;
- укучыларны информацион җәмгыять шартларында эшлекле кеше булып җитешүләренә әзерләү;
- татар телен өйрәнүгә нигез булдыру.

Презентация 10-12 слайдтан торырга мөмкин. Темаларның төрле, матур, кызыклы, мавыктыргыч булуы укучыларда искиткеч зур кызыксыну уята. Матур, тәэсирле итеп бизәлгән презентация укытуның башлангыч этабында зур кызыксыну тудыра. *Презентацияләр күрсәтмәлелек материалларын куллану мәсьәләсен чишәләр.* Мәсәлән, элек рәсемнәрне кисеп тактага магнит ярдәмендә элеп куйсак, хәзер исә Интернет челтәрендә кирәкле картинаны, рәсемне,  хәтта,  видео-сюжет табып, слайдка урнаштырырга мөмкинлек бар. Күрсәтмәлелек күп булса, берничә слайдка урнаштырырга була. Презентацияләр  карау укучыларга бик тә ошый.

Microsoft Power Point презентацияләр төзү программасы - минем иң якын ярдәмчем. Район һәм шәһәр күләмендә оештырылган ИКТ конкурсларында катнашам. Мәсәлән, татар теленнән “Аналитик һәм синтетик җөмләләр” темасына карата төзелгән дәрес-презентация район күләмендә I урынга, шәһәр күләмендә II урынга лаек булды. Бу дәрес-презентациям “Коллекция современных уроков» шәһәр медиафондында урын алды. “Муса Җәлил безнең арабызда” дәрес-презентациясе өчен  I урын бирелде. Укучыларым бу тема белән “Яшь экскурсоводлар” конкурсында катнашып, дипломга лаек булдылар. Укучыларыбызны халкыбызның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен хөрмәт итәргә өйрәтәбез. Шул тәрбияви юнәлештә “Афәрин, мәшһүр Сабантуй!” темасына булдырылган презентациянең җырлы-биюле бәйрәмебезне күңелле итеп уздырырга ярдәме зур булды.

Соңгы 5 ел эчендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларына мөстәкыйль рәвештә укыту чараларын сайлап алу мөмкинчелеге бирелде. Нәтиҗәле укытуга ирешү чарасы буларак, интерактив такта куллану укытучының эшен җиңеләйтә,булыша. SMART Board та тәэмин итүче махсус программа бар. Бу махсус программада 2000нән артык рәсем бирелгән, төрле темаларга тәкъдим ителгән анимацияләр дәресне тагын да мавыктыргыч итәләр. SMART Board интерактив такта кулланып эшләү үз нәтиҗәләрен бирә. Интерактив тактаны яңа материалны аңлатканда, аралашканда киң кулланырга була. 146 нчы мәктәпнең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, педагогия фәннәре кандидаты Р.Н Агмалетдинова “Сыйфат” темасына электрон-интерактив күнегүләр җыентыгын бастырып чыгарды. Мәктәбебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары дәрестә бу җыентыктан бик теләп файдаланалар.

“Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” ТР Законын гамәлгә ашыру юнәлешендә галимнәребез тарафыннан эшләнгән педагогик программаларны куллану буенча шәһәр, республика мөгаллимнәре һәм мәктәп директорлары өчен әледән-әле ачык дәресләр, семинарлар уздырабыз. Мәсәлән, “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләр куллану”, “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәм класстан тыш эшләрдә шәхеснең үзаңын формалаштыру”, “Татар теле һәм әдәбияты укытуның сыйфатлы нәтиҗәсенә ирешү чарасы буларак информацион-коммуникатив технологияләр куллану”, “Татар теле һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын күтәрүдә заманча технологияләр куллану”,”Системалы-эшчәнлекле юнәлеш нигезендә татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрен проектлау”, “Татар теленә өйрәтүдә бигрәк тә “Ана теле”, “Тапкыр”, “Мөмкин”, “Заман”, “Бала” “Татармультфильм” дигән компьютер программаларыннан нәтиҗәле файдаланырга тырышам. Хәзерге заман укытучысы буларак, дөньякүләм Интернет челтәреннән укыту процессы өчен кирәкле материалларны файдаланырга заман таләп итә, мультимедиа технологияләренә караган мәгълүматлар белән эш итәм, алардан дәресләрдә нәтиҗәле файдаланам.

Интегральләшкән дәресләр уздыру мультимедиа технологияләре куллануда иң мөһим мөмкинлекләрнең берсе булып санала. Мәктәбебездә андый дәресләрне компьютер классында үткәрү буенча бай тәҗрибә тупланды. Мәсәлән, инглиз теле укытучысы Низметдинова Р.С. белән “Гомеремне дә бирәм халкыма” темасына интегральләшкән дәрес үткәрдек. Укучыларның белемен, осталык һәм күнекмәләрен тикшерүдә компьютердан файдалану отышлы нәтиҗә бирә.

Димәк, укытучының һөнәри эшчәнлегендә эзләнү, педагогик иҗат өчен офыклар һәрвакыт җитәрлек, һәм тормыш үзе дә информацион технологияләр куллануны таләп итә.